РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.03.2019 № 53-п

Саба муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 21.12.1994 ел, 68-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, эвакуацияләнүче халыкны кабул итү, урнаштыру һәм яшәешен беренчел тәэмин итүне планлаштыру өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. Саба муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын үткәрү турындагы Нигезләмәне расларга (теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына Саба муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын үткәрү турында Нигезләмәне кулланма итеп алырга һәм үтәүгә кабул итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресы буенча Саба муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Р.Н. Минниханов

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башлыгының
25.03.2019 № 53-п
карары белән

**Саба муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын үткәрү турында**
# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

а. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация үткәрү үзенчәлекләре гадәттән тыш хәл чыганагы характеры (җирлекнең радиоактив пычрануы яки химик зарарлануы, җир тетрәү, су басу), гадәттән тыш хәл чыганагының зарарлаучы факторлары тәэсиренең урын-вакыт характеристикалары, чыгарыла торган халыкның саны һәм күләме, эвакуация чаралары үткәрү вакыты һәм кичектергесезлеге белән билгеләнә.

б. Эвакуация үткәрүгә карар кабул итү хокукы Саба муниципаль районы Башлыгы (граждannar оборонасы җитәкчесенә) карамагында.

в. Халыкны эвакуацияләү белән гомуми җитәкчелек Саба муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр комиссиясе аша Гражданнар оборонасы җитәкчесе тарафыннан башкарыла. Эвакуация чараларын турыдан-туры оештыру һәм үткәрү Саба муниципаль районы территориясендә төзелгән эвакуация органнары, муниципаль районның муниципаль берәмлекләре органнары, икътисад объектлары идарәсе органнары тарафыннан Саба муниципаль районы буенча Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсе катнашында тормышка ашырыла.

## 2. Эвакуация органнарын әзерлек хәленә китерү тәртибе

Гадәттән тыш хәл килеп чыгу куркынычы булганда:

эвакуация кабул итү комиссиясенә хәбәр ителә һәм җыела һәм түбәндәге чаралар үтәлә:

комиссиянең җитәкче составының тәүлек буе кизү торуы билгеләнә;

эвакуацияләнергә тиешле халык саны һәм эвакуацияләнүчеләр исемлекләре аныклана;

халыкны транспортның барлык төрләре белән чыгаруга исәп-хисап аныклана;

эвакуация маршрутларын әзерләү оештырыла;

транспортның эвакуация чараларын тәэмин итүгә әзерлеген контрольдә тоту оештырыла;

халыкны җыю пунктлары: эвакуацияләүнең кабул итү (ПЭП) һәм эвакуацияләүнең арадаш пунктлары (ЭАП), вакытлыча урнаштыру пунктлары (ВУП) җәелдерүгә әзерләнә;

элемтә һәм хәбәр итү системасының әзерлеге тикшерелә;

эвакуация җыелу пунктына (ЭҖП) саклау корылмалары әзерләнә;

куркынычсыз районнарда эвакуацияләнүчеләрне урнаштыру пунктлары һәм урыннары әзерләнә.

Эвакуация үткәрү буенча күрсәтмә алу белән:

эвакуация башлануы турында халыкка һәм эвакуация органнарына хәбәр ителә;

килеп туган хәлне исәпкә алып эвакуация чараларын үткәрү тәртибе тәгаенләнә;

эвакуацияләнә торган халыкны исәпкә алу һәм җибәрү һәм эвакуация агымы хәрәкәтен контрольдә тоту оештырыла;

утырту пунктларына транспортны вакытында бирү контрольдә тотыла;

эвакуацияләнгән халыкны куркынычсыз районнарда урнаштыру буенча контроль үткәрелә

Әзерлек срогы (көндез / төнлә, сәгате):

эвакуация кабул итү комиссияләре - 0.30 / 2.00;

оператив төркемнәр - 0.30 / 1.30;

транспорт - 1.00 / 3.00;

эвакуация органнары - 1.00 / 4.00.

## 3. Эвакуация башлану турында халыкка хәбәр итү тәртибе

Саба муниципаль районы территориясендә эвакуация чаралары белән идарә итү даими урнашу пунктыннан (Саба муниципаль районы Башкарма комитеты администрациясе бинасыннан) эвакуация кабул итү комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Эвакуация чараларын үткәрү турында халыкка хәбәр итү Саба муниципаль районы гражданнар оборонасы җитәкчесенең идарә пунктыннан «Игътибар һәркемгә» сигналын һәм телевизион һәм радиотапшырулар челтәре буенча ашыгыч хәбәрләр текстларын тапшыру юлы белән башкарыла. Байлар Сабасы ш.т. б. аерым участоклары һәм урамнары һәм авыл җирлекләре халкына хәбәр итү өчен тавыш көчәйткеч җайланмалары булган район эчке эшләр бүлеге, янгын бүлеге һәм ашыгыч ярдәм машиналары кулланыла. Предприятиеләр, учреждениеләр эшчеләренә хәбәр итү өчен җирле (эчке) радиотапшырулар челтәрләре файдаланыла.

Авария хәлендәге химик-куркыныч матдәләр (АХКМ) булган объектларда авария килеп чыгу куркынычы янаганда, идарә органнарына һәм халыкка хәбәр итү радиотапшыру узелларын һәм урам электросиреналарын кушу, шулай ук АХКМ ташлауның беренчел факторы датчиклары сиренасын кушу белән гамәлгә ашырыла. Элемтә булмаган торак пунктларда күчмә тавыш

көчәйткечләр белән һәм тавыш көчәйткечләре аша хәбәр ителә.

Табигать бәла-казалары килеп чыгу куркынычы булганда, идарә итү органнарына, Россия гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм системасы көчләре һәм чараларына, эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә, халыкка хәбәр итү Саба муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карары белән башкарыла.

Химик яктан куркыныч объектларда авария булганда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы гражданнар оборонасы идарәсе җитәкчесенә, икътисад объектларының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр җитәкчеләре һәм штабларына, район эчке эшләр бүлеге дежурныена, гадәттән тыш хәлләр буенча комиссиягә хәбәр итү барлык элемтә чаралары буенча оештырыла.

### 4. Эвакуацияләнгән халыкны урнаштыру районнары.

Саба муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда халыкны вакытлыча җәмәгать билгеләнешендәге биналарда (кунакханәләр, ял йортлары, кинотеатрлар, спорт корылмалары, тулай торак һ.б.) гадәттән тыш хәл зонасыннан читтә урнаштыру планлаштырыла. Нигездә, эвакуацияләнгән халыкны теркәү урнашу урыннарында башкарыла.

Химик куркыныч объектта (ХКО) авария булган очракта, авария-химик матдә болыты (АХМБ) бик тиз таралу сәбәпле, химик куркыныч объектка якын яшәүче халык куркыныч зонадан чыгарылмый, ә биналарга герметизация үткәрелеп һәм сулыш органнарын саклауның шәхси чараларын кулланып торак (җитештерү һәм хезмәт) биналарының һәм корылмаларының югары яки түбән катларында яшерелә (авария-химик матдә болытының таралу характерына бәйле рәвештә).

### 5. Халыкны чыгару (транспорт белән чыгару) маршрутлары.

Гадәттән тыш хәл килеп туган очракта халыкны чыгару (транспорт белән чыгару) маршрутлары комплекслы тикшерү нәтиҗәләре нигезендә Саба муниципаль районының эвакуация кабул итү комиссиясе рәисе карары белән билгеләнә. Алар автопредприятиеләр җитәкчеләренә һәм халыкка җиткерелә.

### 6. Эвакуация барышында халыкка мәгълүмат һәм инструктаж оештыру.

Эвакуация чорында мәгълүмат эшенең төп бурычы булып халыкны оешкан рәвештә зарарлану урыныннан чыгару (транспорт белән чыгару) тора. Бу максатларда түбәндәгеләргә юнәлдерелгән чаралар тормышка ашырыла:

эвакуация органнары шәхси составыннан үз бурычларын төгәл үтәү, халыкны эвакуацияләү буенча карарлар һәм күрсәтмәләрне үтәү өчен югары җаваплылык хисе саклау;

халыкка эвакуация үткәрү тәртибен һәм кагыйдәләрен аңлату, эвакуацияләнүчеләрне Гражданнар оборонасы сигналлары һәм хакимият органнары боерыклары буенча оешкан рәвештә эшләвен тәэмин итү;

җыелма пунктларда, утырту һәм төшерү пунктларында, поездларда, автомобиль һәм җәяүле колонналарда һәм халык тупланган башка урыннарда

уяулыкны, дисциплинаны һәм тәртипне саклау.

Халыкка мәгълүмат бирүне һәм инструктажны массакүләм мәгълүмат чаралары һәм халык белән шәхси аралашу аша эвакуация органнарының вазыйфаи затлары башкара.